**Тема.** Сугыш- йөрәк ярасы. Геройлар үлмиләр.

**Максат**. Укучыларны Бөек Җиңү һәм Ватан сугышы турында алган белемнәрен тирәнәйтү, Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган язучылар Муса Җәлил, Ф Кәрим һәм җәлилчеләрнең батырлыгын искә төшерү,иҗатларына кызыксыну уяту; туган төбәгебезнең сугыш һәм хезмәт батырлары , аларның батырлыклары турында мәгълүмат бирү; укучыларга Афган һәм Чечня сугышлары,илебез халкына алып килгән югалтулары турында төшендерү; гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиренә,халкына, милләтенә карата мәрхәмәтлелек, горурлык хисе тәрбияләү.

**Кулланылган технология һәм үткәрү формасы**. Иҗади- үстерелешле укыту технологиясе, В. Казыйхановның " Әхлак дәресләре" методик кулланмасы, сыйныф сәгате батырлык һәм әхлак дәресе формасында оештырыла.

**Җиһазлау**. М. Җәлил һәм Ф. Кәрим китапләрыннан куелган күргәзмә,Афганистан геройларына багышланган күргәзмә, плакатлар, ноутбук, Р. Мостафин " Җәлилчеләр" китабы, Җәлилчеләрнең фотосурәтләре, газета- журнал материаллары.

**Сыйныф сәгате барышы**.

**Тәрбияле балалар әдәп илә тәрбияне олыларның сүзләреннән тыш аларның фигыльләреннән дә өйрәнерләр. Һәр хәлләрнедә вә әдәпле кешеләрдән гыйбрәт алып,алар рәвешле булырга тырышырлар. Р. Фәхреддин.**

**1.Башлау. Уку мәсьәләсен кую.**
" Бик сагындым, авылым" җыры( М. Латыйфуллин сүзләре, Р. Сафиуллин көе) яңгырый. Шул вакытта туп шартлаган тавышлар ишетелә.
**Укытучы сүзе.** Узган гасырның легендар битләрен
Кабат актарганда , чал тарих.
Дәһшәтле чорларга алып китсен...
Батырларны кабат искә алыйк.
Кырык беренче ел. Июнь
Йөрәкне тетрәткән бу санны,
Инде яңа гасырга керсәк тә
Күмә алмый еллар тузанны.
- Кадерле укучылар, әлеге яңгыраган шигырь юлларында нинди дәһшәтле еллар турында сүз бара дип уйлыйсыз? Сезнең нинди батырлыклар турында ишеткәнегез бар? Батырлыкларны кайчан һәм кайда күрергә мөмкин? ( Р. Фәхреддинның үгет-нәсыйхәтен уку). Ничек уйлыйсыз, олыларның фигыле дигәнне сез ничек аңлыйсыз? Кемнәрдән үрнәк алырга мөмкин?
- Димәк, укучылар, без бүген сыйныф сәгатендә нәрсә турында сөйләшәбез? Ни өчен бугенге сыйныф сәгатебезне Батырлык һәм әхлак дәресе дип атадык?
**1нче төркем**. Батырлык, кыюлык дигәнне сез ничек аңлыйсыз?
**2 нче төркем**. Әлеге сыйфатлар нинди кешеләргә хас? Батырлык турында сезнең нинди китаплар, кинофильмнар караганыгыз бар?
**11. Уку мәсьәләсен чишү.**
-Татар халкы – искиткеч түземле һәм баһадир халык. Батырлык- милләтебезнең горурланырлык сыйфаты. Татар кешесе беркайчан да Ватанына хыянәт итмәгән. Хәзер сезгә, кадерле укучылар, әлеге фикерләрне дәлилләргә кирәк булачак. Мин сезгә слайдта язылган шигъри юлларны укыргаһәм аның авторын ачыкларга тәкъдим итәм.
**1 төркем**. "Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,

Үлемем дә яңгырар җыр булып”.

**2 төркем .** “ Үләм икән, үкенечле түгел

Бу үлемнең миңа килүе,

Бөек җыр ул- Бөек Ватан өчен

Сугыш кырларында үлүе.”

**Төркемнәрдә эш.**

- Димәк, **1 нче төркемдәге** укучылар М. Җәлил һәм Җәлилчеләр батырлыгы турында , **2 төркемдәге укучылар** Ф. Кәрим турында чыгыш ясыйлар.

**2 слайд**. “ Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска! Моны татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил язды, 1942 елны сугышка килде, һәм, әсирлектә күп газаплар чигеп, кырык үлемнән калып, ахырында Берлинга китерелде. Берлинда , сәяси яшерен оешмада катнашуда , совет пропагандасын таратуда гаепләнде. Ул үләр. Ә аның әсирлектә язган 115 шигыре бар.Шуның алтмышын күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, шигырьләрне яхшылап, дикъкать белән акка күчер, сакла һәм, сугыштан соң Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул. М. Җәлил., 1943, декабрь.( “ Моабит дәфтәрләре”, Җәлилчеләрнең фотосурәтләре күрсәтелә).

**Нәтиҗә**. **Укытучының кереш сүзе**.

-Миллионланган халык белән бергә, Татарстан хезмәт ияләре дә Ватан сагына басалар. Сугышның беренче көннәреннән үк , үзләрен фронтка җибәрүне сорап, Хәрби коммиссариатка ун меңнәрчә гариза килә. Бөек Ватан сугышы елларында 174 мең якташыбыз орденһәм медальлләрбелән бүләкләнә.Батырларның батырларына Герой исеме бирелә. Республикабызда туып-үскән 170 тән артык кеше шушы зур исемгә лаек булды, 50 кеше өч мәртәбә Дан ордены белән бүләкләнде. Безнең дә Әгерҗе төбәгенең горурланырлык батырлары бар. Шуларның берсе- Асаф Габдрахманов**.**

-Ә сүзне хәзер сезнең үзегезгә бирергә телим. Сез бу сыйныф сәгатенә алдан ук хәзерлек эше алып бардыгыз. Һәр төркем бирелгән тема буенча , “Дан Залы” материалларына нигезләнеп, эзләнү эше алып барырга тиеш иде. Сүзне төркемнәрдәге чыгыш ясаучыларга бирәбез.

**Эзләнү эшчәнлеге нәтиҗәләре.**

**1 төркем. 18 нче гасыр. Тирсә восстаниеләре. Пугачев восстаниесе геройлары.**

1.Габделҗәлил Сөләйман улы – 500 кешелек отряд туплап,” ызба” белән идарә иткән.

2. Юскәй Кодаш улы- Тирсә авылы крестьяны. Үз кулы астына 800 кешелек отряд туплый. Гаҗәп укымышлы кешебула, милли азатлык турында бик әһәмиятле фәрманнарны рус теленә тәрҗемә итә. Ижевск, Воткинск заводлары азатлыгы өчен көрәшә.

3.Ярмөхәммәт Кадермәт улы- Пугачев армиясендә полковник яки бригадир дәрәҗәсенә ирешкән өченче татар каһарманы. Ул 2000 отряд җыеп, азатлык өчен көрәштә һәлак була.

**2 төркем чыгышы. 20 гасыр. Гражданнар сугышы чоры батырлары.**

1.Шәймәрдәнов Харис Шәймәрдән улы- 1918-1919 нчы елларда комиссар вазифасын үтәгән.Ак гвардиячеләр тарафыннан җәзалап үтерелгән.

2. Бакиев Баһаветдин Гайнетдин улы –авылның беренче коммунисты, беренче колхоз оештыручысы, укытучы. Аның гәүдәсе зурлап авыл уртасындагы каберлеккә күмелгән.

**3 төркем чыгышы. Бөек Ватан сугышы геройлары.**

1.390 кеше сугышка киткән. Шуларның 295 е туган җирләренә кире әйләнеп кайтмаган. 95 генә туган авылына кире әйләнеп кайткан.

2 . Кызыл Йолдыз ордены белән 5 кеше, Сугышчан батырлыклар өчен ордены белән 2 кеше бүләкләнгән.( Исемнәре атала).

3. Бер укучы әбисенә багышлап язылган “ Әбием батырлыгы” дигән мәкаләсен укый.

**4 төркем чыгышы. Хезмәт батырлары.**

- Тырыш хезмәтләре өчен медале белән терлекчеләр Әхмәдиева Синара Ситдик кызы, Гатауллина Сәлимә Муллаян кызы бүләкләнә.

Ленин ордены белән Шәмсетдинов Юзленур Шәмсетдин улы бүләкләнә.

Хезмәт Даны ордены белән авылыбызның 11 кешесе бүләкләнә. ( Исемнәре атала)

**Укытучы сүзе.**

Укучылар, хәзер тормышыбыз  тынычмы?  Бүгенге тормышта сез батырлар ны очрата аласызмы? Сезне түбәндәге мәгълүматлар белән таныштырып  китәм. Бу саннар нинди вакыйга белән бәйле? 1980 нче елда Әфганистан җирендә 1500. 1981 елда -1300, 1982 елда 2 000 гә якын кешеһәлак була. Яралыларның саны уннарча меңгә җитә. 1983 елда 1500, 1984 елда 2400 гә якын кеше туган туфрагына алып кайтып күмелә. Татарстан Республикасы да Әфган сугышында 257 егетен югалтты.

**5 төркем чыгышы.**

- Безнең  авылыбызның 8 егете дә Әфган ,ә 8 е Чечня  сугышында катнашты.  Безнең мәктәптә белем алган Фатыхов Раушан  Чечня җирендә батырларча һәлак булды. Безнең мәктәпнең  Дан Залында аның хатлары саклана һәм аңа мемориал такта куелган. (Армия сафларыннан кайтуына өч ай кала, 2004 нче елның 5 нче июлендә Чечня сугышында һәлак булган Кырынды авылы егете Фатыйхов Раушанның якты истәлегенә багышлап  бер укучы Әмир Хәсәновның “ Раушанның соңгы хаты” дип исемләнгән бәетен укый.)

-Кадерле укучылар, батырлар безнең янәшәдә генә йөри. Бүген бездә кунакта Әфган сугышында катнашкан, Сугышчан батырлыклары өчен ордены белән бүләкләнгән авылдашыбыз, тормыш нигезләре укытучысы Гарифуллин Рәшит Миншат улы кунакта. Сүзне хөрмәтле кунагыбызга бирәбез.

**3.Үзбәя. Рефлексия**.

- Укучылар, Батырлык дәресебез ахырына якынлашты. Бүгенге дәресебездә сез нинди яңа белемнәр үзләштердегез?  Тормышыгызга кирәкле нинди сыйфатларга ия булдыгыз? Батырлык сыйфаты тормышта ниөчен кирәк дип уйлыйсыз? Ә сез үзегез батырмы?

**Йомгаклау өлеше.**

**Сугышларда һәлак булган авылдашларыбыз хөрмәтенә бер минутлык тынлык игълан ителә.**

**Укытучының йомгаклау сүзе.**

-Җир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын. Яшь  егетләрнең гомерләре вакытсыз өзелмәсен,әти-әниләр  кайгы яше түкмәсен.Кеше буднньяга иҗат итү, җирне матурайту, изгелекләр эшләр өчен яратылган. Дөньяда яхшылык кылып яшәү- үзе батырлык.

**Нәтиҗә.**

**Кулланылган  әдәбият.**

1.“ Ачык дәрес” газетасы. Укытучылар өчен татар телендә методик ярдәмлек.Июн, 2008 ел, май, 2009 нчы ел.

2.“ Балаларга үгет- нәсыйхәт” китабы. Казан. “ Дом печати” нәшрияты, 1988- 263 бит.

3.Җәләлиев.Ш. Ш.Татар халык педагогикасы.Казан:Мәгариф,1997 – 175 бит.

4.З. Х Хабибуллина. Сәхнәләрдән әйтер сүз. 5- 11 сыйныфлада татар теле һәм әдәдбиятыннан дәрестән тыш эшләр. Укытучылар өчен кулланма.- Казан: Мәгариф, 2008,- 127 бит.

5.Мостафин.Р. Ә. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты.- Казан,Татар китап нәшр. 1988-263 бит